**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7558**
**17.12.2018**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында халыкның пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннарын билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 7004 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чорында халыкның пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннарын билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 7004 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 15 декабрендәге 6769 нчы, 2017 елның 13 декабрендәге 7811 нче карарлары редакциясендә), 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Халыкның махсуслаштырылган кибетләрдә яки кибетләрнең махсуслаштырылган бүлекләрендә ирекле сату рөхсәт ителә торган I-III класс куркынычлы (куркыныч зона радиусы 0,5 тән 20 метрга кадәр) көнкүреш пиротехник эшләнмәләрдән файдалану урыннарын билгеләргә:

1) «Җиңү паркы» – чыршы янындагы әйләндереп алынган спорт мәйданчыгы («Шахмат-Шашка клубы» административ бинасыннан 300 м көнбатышта, 20/07 нче торак йорттан 750 м көньякта);

2) Шәһәр пляжы янындагы мәйданчык (Раскольников урамы, 60 нчы йорт адресы буенча 3 этажлы Таунхаус бинасыннан 350 м көньяк-көнбатышта, 38/05 нче торак йорттан 400 м көнбатышта);

3) «Төзүче» БЯСМ» МАӨББУ стадионы артындагы мәйданчык (Мәләкәс елгасы яр буенда «Төзүче» БЯСМ» МАӨББУ стадионынан 300 м көнчыгышта, «Яр Чаллы сәнгать колледжы» ДАҺББУдан 350 м көньяк-көнчыгышта)».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин